**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 18 июнендәге 2090 номерлы карары**

**Казан шәһәрендә «Ак Барс Арена» стадионында концерт үткәрү чорында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны чикләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. кирәк булганда, 2026 елның 20 июнендә 06:00 сәгатьтән 23:59 сәгатькә кадәр түбәндәге участокларда транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны чикләүне кертергә:

1.1.1. Сибгат Хәким урамы буенча, Фатыйх Әмирхан Чистай урамына кадәрге участокта;

1.1.2. Чистай урамы буенча, Абдулла Бичурин урамыннан Ямашев проспектына кадәрге участокта, Абдулла Бичурин урамыннан хәрәкәт иткәндә (Сибгат Хәким урамына таба Фатыйх Әмирхан урамына чыгу юлыннан кала);

1.1.3. Чистай урамында, Ямашев проспектыннан Адоратский урамына кадәрге участокта, Ямашев проспектыннан хәрәкәт иткәндә;

1.1.4. Ямашев проспекты буенча, Адоратский урамыннан Себер Тракты урамына кадәрге участокта;

1.1.5. Гаврилов урамындагы дублер юлда, Маршал Чуйков урамыннан Чистай урамына кадәрге участокта;

1.1.6. Академик Арбузов урамында, Журналистлар урамыннан Ямашев проспектына кадәрге участокта, Журналистлар урамы ягыннан хәрәкәт иткәндә;

1.1.7. «Ак Барс Арена» стадионы янындагы җирле юл буенча;

1.2. юл хәрәкәтен оештыруда техник чараларны һәм таранга каршы техниканы урнаштыру өчен концертны оештыручы (алга таба – Оештыручы) җаваплы дип билгеләргә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе белән берлектә (Р.Х.Шәмсетдинов) Оештыручыга йөк техникасы һәм (яисә) таранга каршы блоклар бирүдә ярдәм күрсәтергә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.4.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыруда һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплауда Оештыручыга ярдәм күрсәтергә;

1.4.2. транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.4.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән участокта шәхси мобильлек чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны тыю эшен оештырырга;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре урам-юл челтәренең күрсәтелгән участогында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**